**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22, факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ___________ ПР-40 26.02.2025 КАРАР № _____

Башкарма комитетның «2025 елга «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 21 октябрендәге ПР-224 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 07 февралендәге 5600-МР номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында азык-төлек продуктларына өстәмә индексация турында һәм Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын финанслауның норматив принцибын гамәлгә ашыру буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарның 5 пунктын, 1 нче кушымта нигезендә алмаштырырга.;
2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш. Бариев

1 нче кушымта

5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативлары

| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының эш сәгатьләре | Азык-төлек продуктларына, тәрбияләнүчегә/көнгә (сум)чыгымнар нормативы | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомумүсеш төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәге) | | шифаханә төркемнәре | |
| | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр |
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | 0 | 0 |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | 0 | 0 |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36 |